РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422054, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт

тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

17.01.2019 №1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге Советы тарафыннан
2014 нче елның 01 нче мартында кабул ителгән
7 нче номерлы карары белән расланган
“Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлегенең
муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның
һәм муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи
хәлләренә яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын
үтәүгә бәйле бүләк алуы, бүләк тапшыру һәм бәяләү,
сату (сатып алу) һәм аны тормышка ашырудан кергән
акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе турында
Нигезләмә»сенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законның 2 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында " 2018 елның 30 октябрендәге 387-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештәТатарстан Республикасы Саба районы прокуратурасының 2019 нчы елның 15 нче январенда чыгарылган №07-08-02-4-19 нчы номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Олы Шыңар авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы тарафыннан 2014 нче елның 01 нче мартында кабул ителгән 7 нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хәлләренә яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле бүләк алуы, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны тормышка ашырудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмә»сенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 2 абзацында «хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләрен "даими (штат) нигездә комиссиядә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны "Интернет"мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Олы Шыңар авыл җирлеге биләмәсендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

4.Карарның үтәлешен тикшерүне үз естемә алам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов